КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 24 июнь г.Казань № 452

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карары белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенцияләр рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 декабрь, 1305 нче; 2023 ел, 11 март, 228 нче, 2023 ел, 27 апрель, 537 нче, 2024 ел, 28 март, 195 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясында каралган тәртиптә эшсез дип танылган Россия Федерациясе гражданнарына социаль

түләүләрне гамәлгә ашыру буенча тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану тәртибе (алга таба - тиешенчә Тәртип, эшсез гражданнар) эшсез гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция (алга таба – субвенция) рәвешендә бирелә торган акчалардан файдалану механизмнарын билгели.»;

4 пунктта:

бишенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча картлык буенча хезмәт пенсиясенә, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган картлык буенча хезмәт пенсиясенә хокук бирә торган яшькә җиткәнчегә кадәр чорга Татарстан Республикасы халыкны эш белән тәэмин итү хезмәте дәүләт учреждениеләре (алга таба - дәүләт учреждениеләре) тәкъдиме буенча эшсез гражданнарга билгеләнгән пенсияне түләү һәм вафат булган пенсионерларны күмү буенча хезмәт күрсәтүләр хакын түләү буенча социаль пособиеләрне түләү;»;

сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы (алга таба - Министрлык) буйсынуындагы хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү;»;

7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Картлык буенча иминият пенсиясенә, шул исәптән вакытыннан алда билгеләнә торган, хокук бирә торган яшькә җиткәнче чорга дәүләт учреждениеләре тәкъдиме буенча эшсез гражданнарга билгеләнгән пенсияне түләүгә субвенцияне тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе пенсия һәм социаль иминият фондының аның билгеләнүенә бәйле чыгымнарын каплау юлы белән гамәлгә ашырыла.».

Татарстан Республикасы<br>
Премьер-министры<br>
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин